**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 19 гыйнварындагы 96 номерлы карары**

**«Канализация-насос станциясен төзеп,
Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе
челтәрләрен үзгәртеп төзү» линия объекты территориясен
планлаштыру проектын раслау турында**

Территорияне шәһәр төзелеше документлары белән тәэмин итү максатыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 апрелендәге 575 номерлы «Территорияне планлаштыру документларын, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнарын әзерләү, килештерү, раслау, аларның гамәлдә булу вакытларын озайту, капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр, файдалануга кертүгә рөхсәтләр бирү үзенчәлекләре турында»гы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 11 ноябрендәге 933 номерлы «Раслау турындагы карар Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә җирле үзидарә органнары тарафыннан кабул ителә торган территорияне планлаштыру проектлары һәм территорияне ызанлау проектлары, мондый территорияне планлаштыру проектларына һәм территорияне ызанлау проектларына үзгәрешләр кертү җәмәгатьчелек белән фикер алышулар яисә ачык тыңлаулар уздырмыйча раслана торган очракларны билгеләү турында»гы карары нигезендә, «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2025 елга муниципаль биремен исәпкә алып **карар бирәм**:

1. «Канализация-насос станциясен төзеп, Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрләрен үзгәртеп төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проектын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, планлаштырылган линия объектын урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлегеннән (хезмәт урынында файдалану өчен материаллар) кала, «Муниципаль хокукый

актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 19 гыйнварындагы
96 номерлы карарына
кушымта

**«Канализация-насос станциясен төзеп, Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрләрен үзгәртеп төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты**

«Канализация-насос станциясен төзеп, Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрләрен үзгәртеп төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проектының төп өлеше түбәндәгеләрдән тора:

I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш. Линия объектларын урнаштыру зоналары чикләре сызымы.

II. Линия объектын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге белән линия объектын урнаштыру турында нигезләмә.

Линия объектын план буенча урнаштыру зонасы чикләренең характерлы нокталары исемлеге хезмәт урынында файдалана торган материаллар булып тора һәм «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырылырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырылырга тиеш түгел.

# I. Территорияне планлаштыру проекты. График өлеш.
## Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләре сызымы




**ШАРТЛЫ БИЛГЕЛӘР**

| | |
|---|---|
| | Территорияне планлаштыру проектын әзерләү гамәлгә ашырыла торган территория чиге |
| | Линия объектларын план буенча урнаштыру зонасы чиге |
| | Җир кишәрлеге чиге |
| | Урам-юл челтәренең гамәлдәге кызыл линиясе |
| | Басымлы яңгыр канализациясе |
| К2Н | Басымлы яңгыр канализациясе |
| Кл | Бетерү планлаштырылган яңгыр канализациясе |
| | КНС – канализация насос станциясе |
| | Инженерлык инфраструктурасы объектлары зонасы |
| 1 ● | Характерлы нокта номеры |
| 16:50:110406:14 | Җир кишәрлегенең кадастр номеры |

## II. Линия объектын урнаштыру турында нигезләмә

### Линия объектларының, шулай ук урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларының исемнәре, төп характеристикалары һәм билгеләнеше

«Канализация-насос станциясен төзеп, Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрен үзгәртеп төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты «Казан шәһәрен үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесенең 2025 елга муниципаль биреме нигезендә әзерләнде. Ул Татарстан Республикасы Казан шәһәре Яңа Савин районында яңгыр канализация челтәрен урнаштыруны күздә тота.

Линия объекты территориясен планлаштыру проекты түбәндәге документлар нигезендә башкарылды:

- 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы;
- 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Россия Федерациясенең Җир кодексы;
- Казан шәһәре Думасының 2020 елның 28 февралендәге 5-38 номерлы карары белән расланган Казан шәһәр округының Генераль планы;
- Казан шәһәре Думасының 2021 елның 16 августындагы 5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәренең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре

Проектны эшләү өчен беренчел мәгълүматлар проект-смета документларын эшләү өчен техник биремдә бар.

Картографик материал МСК-16 җирлек координаталары географик системасында башкарылды.

Проектлаштыру участогында җирле әһәмияттәге капиталь төзелеш объектлары, шулай ук федераль һәм төбәк әһәмиятендәге капиталь төзелеш объектлары юк.

«Канализация-насос станциясен төзеп, Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрен үзгәртеп төзү» линия объекты территориясен планлаштыру проекты чикләренең мәйданы 12051 кв.м тәшкил итә.

«Канализация-насос станциясен төзеп, Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрен үзгәртеп төзү» линия объектын план буенча урнаштыру зонасының гомуми мәйданы 3000 кв.м тәшкил итә.

Территориядән агып төшә торган яңгыр сулары агынты суларны ябык яңгыр канализация челтәренә чыгару өчен хезмәт итүче яңгыр суларын җыю коелары аша чыгарыла.

Яңгыр суларының канауга агуын булдырмау максатыннан проектта яңгыр канализациясенең булган коллекторын күчерү тәкъдим ителә.

Маршал Чуйков урамында проектлана торган ø1200 мм лы яңгыр канализациясе челтәренең озынлыгы – 90 м.

Казан шәһәре Башкарма комитеты Тышкы төзекләндерү комитетының 2025 елның 14 февралендәге 02-41/463 номерлы хаты буенча яңгыр канализациясенең насос станциясе егәрлеге, резервуарларның күләме һәм габаритлары, басым линияләренең диаметрлары, аларның салыну тирәнлеге тиешле проект-смета документларын эшләгәндә төгәлләштерелергә тиеш.

Яңгыр канализациясе челтәре участогын төзү һәм канализация-насос станциясен урнаштыру Җиңү паркы һәм Маршал Чуйков урамы территориясеннән ага торган яңгыр суларын җыюны тәэмин итү зарурлыгыннан килеп чыга.

Проектта Маршал Чуйков урамында яңгыр канализациясе челтәрләрен үзгәртеп кору, җыя торган резервуар һәм ике басымлы линия белән яңгыр канализациясе насос станциясен урнаштыру, Маршал Чуйков урамындагы ø1000 мм коллекторга тоташтыру каралган.

Ике проектлана торган басымлы линиянең озынлыгы 2х180 м тәшкил итә.

Шулай ук проектта парк чикләрендә ø1200 мм яңгыр канализациясе челтәрләрен сүтү тәкъдим ителә, озынлыгы 430 м.

Линия объекты территориясен планлаштыру проекты чикләрендә аларның урнашу урынын үзгәртү белән бәйле линия объектларын реконструкцияләү таләп ителми.

**Территорияләрендә линия объектын план буенча урнаштыру зонасы билгеләнә торган Россия Федерациясе субъектлары исемлеге, Россия Федерациясе субъектлары составындагы муниципаль районнар, шәһәр округлары исемлеге, федераль әһәмияттәге җирлекләр, торак пунктлар, шәһәр эчендәге территорияләр исемлеге**

Линия объектын урнаштыру зонасы Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләрендә билгеләнә.

**Урнашу урыны үзгәрүгә бәйле рәвештә реконструкцияләнергә тиешле линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләренең характерлы нокталары координаталары исемлеге**

Линия объекты территориясен планлаштыру проекты чикләрендә реконструкцияләнергә тиешле линия объектлары юк.

**Линия объектларын план буенча урнаштыру зоналары чикләрендә линия объектлары составына керә торган капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең чик параметрлары**

Планлаштыру проекты чикләрендә капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү каралмаган.

**Территорияне планлаштыру проектын әзерләү вакытына гамәлдә булган һәм төзелеп килүче саклана торган капиталь төзелеш объектларын (бина, корылма, төзелеше тәмамланмаган объектлар), шулай ук территорияне планлаштыру буенча элек расланган документлар нигезендә төзү планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектларын линия объектын урнаштыру белән бәйле рәвештә мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау чараларын гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Территорияне планлаштыру проекты чикләрендә капиталь төзелешнең сакланып калган һәм төзелә торган объектлары, шулай ук төзү өчен планлаштырылган объектлар юк.

Резервуарлар төзү планлаштырыла. Аларның күләмнәре проектның алдагы стадиясендә төгәлләштерелергә тиеш.

Яңгыр канализациясе челтәрен салу өчен башка коммуникацияләр белән кисешүләр исәпкә алынырга тиеш.

Эш урынында проект документларында күрсәтелмәгән җир асты коммуникацияләре табылганда, эшләр туктатылырга, коммуникацияләрнең кайсы затка каравы билгеләнергә һәм урынга эксплуатацияләүче оешма вәкиле чакырылырга тиеш.

**Линия объекты урнашуга бәйле рәвештә мәдәни мирас объектларын мөмкин булган тискәре йогынтыдан саклау буенча чараларны гамәлгә ашыру кирәклеге турында мәгълүмат**

Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән мәдәни мирас объектлары, ачыкланган мәдәни мирас объектлары, шулай ук проектлау территорияләрендә һәм янәшәдәге территорияләрдә мәдәни мирас объекты билгеләренә ия булган объектлар юк.

Яңадан ачыкланган тарихи-мәдәни мирас объектлары булганда, проект документларына үзгәрешләр кертеләчәк.

**Әйләнә-тирә мохитне саклау чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Проектлаштыру өстендә эшләүнең алдагы этапларында планлаштырылган яңгыр канализациясе насос станциясе өчен санитар-ял зоналарын билгеләү зарурлыгы булмауны раслау өчен санитар-ял зонасы проектын эшләү тәкъдим ителә.

**Территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, шул исәптән янгын куркынычсызлыгын һәм гражданнар оборонасын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру зарурлыгы турында мәгълүмат**

Линия объекты территориясен планлаштыру проекты чикләрендә атом энергиясен файдалану объектлары (шул исәптән атом-төш җайланмалары, атом-төш материалларын һәм радиоактив матдәләрне саклау пунктлары, радиоактив калдыкларны саклау пунктлары), Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә торган куркыныч җитештерү объектлары, аеруча куркыныч, техник яктан катлаулы, уникаль объектлар, оборона һәм иминлек объектлары юк.

2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының (2025 елның 31 июлендәге редакциядә) 48 статьясының 14 пункты нигезендә әлеге объект өчен «Гражданнар оборонасы буенча чаралар, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү буенча чаралар исемлеге» бүлеген эшләү таләп ителми.